СОВЕТ
ТУКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ТУКАЙ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

пр. М. Джалиля, 46, г. Набережные Челны, 423800

М. Җәлил пр., 46, Яр Чаллы шәһәре, 423800

Телефон/факс (8552) 70-37-82, tukay@tatar.ru

29.03.2019 № 31/12
На № __________ от ______________

# КАРАР

**«Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә территориаль иҗтимагый үзидарәне оештыру тәртибе турында**

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ санлы Федераль закон нигезендә, Тукай муниципаль районында яшәүчеләрнең җирле үзидарәне гамәлгә ашыруда катнашу хокукларын тәэмин итү, Тукай муниципаль районында территориаль иҗтимагый үзидарәне гамәлгә ашыру өчен хокукый һәм оештыру нигезен булдыру максатында, муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә территориаль иҗтимагый үзидарәне оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен кушымтадагыча расларга.
2. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (http://tukay.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга (http://pravo.tatarstan.ru).
3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, хокук тәртибе, милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет Рәисе — Ф.М. Камаев

Тукай муниципаль районы Советының
2019 елның 29 марта 2019
31/12 санлы карарына кушымта

# «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә территориаль иҗтимагый үзидарәне оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибе

## 1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

### 1 маддә. Әлеге тәртипнең гамәлдә булу өлкәсе

Әлеге нигезләмә Тукай муниципаль районы территориясендә территориаль иҗтимагый үзидарәне оештыру һәм гамәлгә ашыру, гамәлгә ашыруны туктату белән белән бәйле мөнәсәбәтләрне җайга сала.

Әлеге нигезләмә җирле үзидарәнең Европа Хартиясе, Россия Федерациясе Конституциясе, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ санлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ЗРТ санлы Законы, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка закон актлары, район Уставы, әлеге нигезләмә, районның башка норматив хокукый актлары (алга таба - норматив хокукый актлар) нигезендә эшләнгән.

### 2 маддә.Территориаль иҗтимагый үзидарә

1. Территориаль иҗтимагый үзидарә - җирле билгеләнештәге сораулар буенча мөстәкыйль һәм үзләренең җаваплылыгында шәхси инициативаларны гамәлгә ашыру өчен, территория өлешендә яшәү урыннары буенча гражданнарның үзоешуы.
2. Территориаль иҗтимагый үзидарәне гамәлгә ашыру хокукына уналты яшькә җиткән тиешле территориядә яшәүчеләр ия.
3. Гражданинның территориаль иҗтимагый үзидарәне гамәлгә ашыру хокукы түбәндәге хокукларны үз эченә ала:

1) инициатор булырга, үзе яшәгән территориядә территориаль иҗтимагый үзидарә оештыруда катнашырга;
2) территориаль иҗтимагый үзидарә тарафыннан уздырылган гражданнар җыелышларында (конференцияләрендә) катнашырга;
3) территориаль иҗтимагый үзидарә органнарына сайларга һәм сайланырга;
4) территориаль иҗтимагый үзидарә эшчәнлеге турында мәгълүмат алырга;
5) Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары, муниципаль хокукый актлар, территориаль иҗтимагый үзидарә уставы нигезендә башка хокуклар.

### 3 маддә. Территориаль иҗтимагый үзидарәне гамәлгә ашыру принциплары

Районда территориаль иҗтимагый үзидарә түбәндәге принципларда гамәлгә ашырыла:

1) законлылык;
2) иреклелек;
3) кеше һәм гражданинның хокукларын һәм ирекләрен саклау һәм яклау;
4) җәмәгатьчелек фикеренең ачыклыгы һәм исәпкә алынуы, территориаль иҗтимагый үзидарә органнарының сайлап куелуы һәм контрольдә булуы;
5) тиешле территория халкы мәнфәгатьләренең бөтен муниципаль берәмлек халкы мәнфәгатьләре белән туры килүе;
6) җирле билгеләнештәге сораулар буенча шәхси инициативаларны кабул иткәндә һәм гамәлгә ашырганда мөстәкыйльлек һәм җаваплылык;
7) территориаль иҗтимагый үзидарәнең җирле үзидарә органнары белән уңышлы үзара бәйләнеше;
8) халыкның территориаль иҗтимагый үзидарәне гамәлгә ашыру формаларын сайлау иреге;

9) гражданнарның җыелышларда, конференцияләрдә ирекле белдерүләре.

2. Әлеге маддәнең 1 өлешендә санап үтелгән принциплар җирле үзидарә органнарының норматив хокукый эшчәнлеге һәм территориаль иҗтимагый үзидарәнең гамәли эшчәнлеге нигезе булып тора.

**4 маддә. Территориаль иҗтимагый үзидарәнең максатлары, бурычлары һәм төп эшчәнлек юнәлешләре**

1. Территориаль иҗтимагый үзидарәнең максатлары:

1) җирле билгеләнештәге сорауларны хәл итүгә гражданнарны турыдан-туры яшәү урыны буенча җәлеп итү;

2) кешенең яшәү мохите сыйфатын турыдан-туры яшәү урыны буенча яхшырту;

3) район халкында үз файдалануында булган муниципаль милеккә һәм торак-коммуналь хуҗалык объектларына җаваплы мөнәсәбәт формалаштыру;

4) Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары, муниципаль хокукый актлар нигезендә башка максатлар.

2. Территориаль иҗтимагый үзидарә эшчәнлеге бурычларына аның уставы белән түбәндәгеләр керегә мөмкин:

1) территориаль иҗтимагый үзидарә компетенциясенә аның уставы белән кергән сорауларны хәл итү;

2) җирле билгеләнештәге сорауларны хәл итү буенча халыкның шәхси инициативаларын гамәлгә ашыру өчен җәмәгать эшләрен оештыру;

3) территориаль җтимагый үзидарә эшчәнлеге өчен кирәкле мәгълүматны алу һәм тарату;

4) муниципаль берәмлек җирле үзидарә органнары һәм ТР дәүләт хакимияте органнары белән үзара бәйләнеш;

5) территориаль иҗтимагый үзидарә гамәлгә ашырылган территориядә муниципаль хезмәтләрнең эшен камилләштерү буенча тәкъдимнәр эшләү һәм кертү;

6) халык фикерен ачыклау, шул исәптән сорашулар уздыру, анкеталар тутыру;

7) территориаль иҗтимагый үзидарә гамәлгә ашырылган территория торышын контрольдә тоту;

8) торак-көнкүреш характерындагы сорауларны хәл итүдә гражданнарга булышлык күрсәтү.

3. Территориаль иҗтимагый үзидарә эшчәнлеге территориаль иҗтимагый үзидарә көчләре белән мөстәкыйль хәл итерлергә мөмкин булган бурычларны хәл итүгә юнәлтелергә һәм турыдан-туры җирле билгеләнештәге сораулар белән бәйле булырга тиеш. Мондый эшчәнлекнең төп юнәлешләренә түбәндәгеләр кертелергә мөмкин:

1) көнкүреш калдыкларын утильләштерү һәм эшкәртү мәсьәләләрен, яшелләндерүне, ишегалды территорияләрен һәм урамнарны яктыртуны, ишегалды инвентарен төзекләндерүне һәм җиһазландыруны кертеп, территориаль иҗтимагый үзидарә территориясен төзекләндерү;

2) ял итү урыннарын, уен һәм спорт мәйданчыкларын булдыруны, түләүсез лекцияләр, китаплар, фильмнар белән алмашуны оештыру, мәдәни, спорт һәм башка ял чараларын оештыруны һәм уздыруны (шул исәптән балалар һәм яшьләр өчен) кертеп, халыкның ял итү мөмкинлекләрен арттыруга ярдәм итү;

3) җәмәгать тәртибен саклау буенча ирекле кизүлекне, хокук саклау органнарына гражданнарның законсыз гамәлләр кылуы турында мәгъүмат бирүне, янгын сүнедерүдә ярдәм итүне, табигать бәла-казалары нәтиҗәләрен ликвидацияләүне кертеп, территориаль иҗтимагый үзидарә территориясе чикләрендә гражданнар тормышы куркынычсызлыгын арттыру буенча чараларда катнашу;

4) ярдәмгә мохтаҗларны ачыклауны, хәлдән килгәнчә ярдәм күрсәтүне, хәйрия, мәрхәмәт акцияләрен оештыруны, оешмаларга һәм гражданнарга мондый акцияләрне уздыруда булышлык күрсәтүне, социаль яклау органнарына әлеге өлкәдәге территориаль иҗтимагый үзидарә үз көче белән хәл итә алмаган проблемалар турында мәгълүмат бирүне кертеп, гражданнарның социаль яклаусыз категориясенә кергән кешеләргә (өлкәннәргә, инвалидларга, аз

тәэмин ителгәннәргә, шулай ук күп балалы гаиләләргә) һәм башка авыр тормыш хәлендә калган кешеләргә ярдәм итү.

4. Әлеге маддәнең 1-3 өлешләрендә санап кителгән территориаль иҗтимагый үзидарә эшчәнлегенең максатлары, бурычлары һәм төп юнәлешләре тулы яки махсус түгел һәм территориаль иҗтимагый үзидарә уставын эшләгәндә аларның күләмен һәм эчтәлеген үзгәртүгә гражданнарның хокукларын чикләми.

## 2 бүлек. Территориаль иҗтимагый үзидарәне оештыру, уставын теркәү һәм территориаль иҗтимагый үзидарәне бетерү

### 5 маддә. Территориаль иҗтимагый үзидарәне оештыру тәртибе

1. Территориаль иҗтимагый үзидарәне оештыру максатыннан, гражданнарның 10 кешедән ким булмаган инициатив төркеме оеша.

2. Инициатив төркем:

1) Район Башлыгы адресына территориаль иҗтимагый үзидарә оештыру нияте турында түбәндәгеләрне үз эченә алырга тиешле хәбәрнамә юнәлтә:

- күрсәтелгән территориядә яшәүче гражданнарның саны турында мәгълүмат бирүгә запрос;
- инициатив төркем турында мәгълүматлар (фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган елы, паспорт яки гражданин паспортын алыштыручы документның сериясе, номеры һәм бирү датасы, яшәү урынының адресы, территориаль иҗтимагый үзидарәне гамәлгә ашыру ниятләнгән территориядә яшәү фактын раслаучы документ);

2) территориаль иҗтимагый үзидарә уставы проектын эшләүне гамәлгә ашыра һәм территориаль иҗтимагый үзидарәне гамәлгә ашыру ниятләнгән территориядә яшәүче гражданнарның җыелышын (конференциясен) чакыруны оештыра;

3) Тукай муниципаль районы Советы тарафыннан территориаль иҗтимагый үзидарәнең территориаль чикләре билгеләнгәннән соң, гражданнар җыелышын (конференциясен) хәзерләүне һәм уздыруны гамәлгә ашыра.

3. Территориаль иҗтимагый үзидарә оештыру нияте турында хәбәр иткәннән соң, инициатив төркем эшнең теләсә кайсы этабында, территориаль иҗтимагый үзидарә уставын эшләүдә, гражданнар җыелышын (конференциясен) әзерләүдә һәм уздыруда оештыру, методик һәм консультатив ярдәм сорап, муниципаль берәслек Советына, Башкарма комитететына мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

4. Башкарма комитет тарафыннан территориаль иҗтимагый үзидарә уставы теркәлгән мизгелдән территориаль иҗтимагый үзидарә оешкан санала.

### 6 маддә. Территориаль иҗтимагый үзидарә территорияләре һәм чикләре

Территориаль иҗтимагый үзидарә халык тарафыннан турыдан-туры гражданнар җыелышын (конференциясен) уздыру юлы белән, шулай ук территориаль иҗтимагый үзидарә органнарын гражданнар яшәгән түбәндәге территория чикләрендә төзү юлы белән гамәлгә ашырыла:

1) күпфатирлы торак йорт подъезды;
2) күпфатирлы торак йорт;
3) торак йортлар төркеме;
4) торак микрорайон;
5) авыл җирлеге булмаган торак пункты;
6) гражданнар яшәгән башка территорияләр.

2. Территориаль иҗтимагый үзидарә гамәлгә ашырылган территория чикләре район Советы тарафыннан әлеге территориядә яшәүчеләр тәкъдиме буенча билгеләнә. Чикләрне билгеләгәндә (үзгәрткәндә), территория бөтенлегенең тарихи, мәдәни, социаль-икътисадый һәм башка сыйфатлары исәпкә алынырга мөмкин.

3. Территориаль иҗтимагый үзидарә гамәлгә ашырыла торган территория чикләре аерылмас булырга тиеш (әгәр аның составына бердән артык торак йорт керә икән).

4. Территориаль иҗтимагый үзидарә гамәлгә ашырыла торган территория чикләре муниципаль берәмлек чикләреннән чыга алмый.

5. Билгеләнгән тәртиптә предприятиеләр, учреждениеләр, оешмаларга беркетелгән территорияләрдә территориаль иҗтимагый үзидарә тиешле җир участогының хокук иясе белән килешү буенча гамәлгә ашырыла.

6. Район Советы территориаль иҗтимагый үзидарә территориясе чикләрен билгеләргә яисә территориянең башка нигезләнгән вариантын район Советына хәбәр кергән көннән алып 2 айдан да соңга калмыйча күрсәтергә тиеш. Әлеге мәсьәләне утырышка чыгару район Советы регламенты таләпләре нигезендә гамәлгә ашырыла.

Каршылыклар килеп чыккан очракта, чикләрен билгеләү турында мәсьәләне өстәмә өйрәнү кирәк булганда, әлеге мәсьәләне карау срогы район Советының киләсе утырышына кадәр озайтылырга мөмкин.

8. Район Советы территориаль иҗтимагый үзидарә чикләрен билгеләү турында инициатива төркем тәкъдимен түбәндәге очракларда кире кагарга хокуклы:

1) әгәр инициатив төркем тәкъдим иткән территория территориаль иҗтимагый үзидарә чикләрен билгеләү турында карар кабул ителгән территория белән тәңгәл килсә (әлеге тәртипнең 8 маддәсе 18 өлеше белән каралган нигезләр буенча әлеге карарны гамәлдән чыгару очрагыннан тыш);

2) әгәр инициатив төркем тәкъдим иткән территориядә торак йортлар бөтенләй булмаса;

3) әгәр әлеге нигезләмәнең 7 маддәсе 1 өлешендә каралган тәртиптә һәм срокларда инициатив төркем тәкъдиме тиешле территориядә яшәүче гражданнар җыелышы беркетмәсе белән расланмаса.

Әлеге тәртипнең 5 маддәсе 2 өлеше 1 пунктында күрсәтелгән мәгълүматлар инициатив төркем тарафыннан тулы күләмдә тапшырылмаган очракта, чикләрне билгеләү турында тәкъдимне карау срогы документларның тулы комплектын тапшырган көннән санала.

Инициатив төркем тарафыннан ышанычсыз мәгълүматлар тапшырылган очракта, документлар инициатив тәркемгә кайтарыла, чикләрне билгеләү турында тәкъдим каралмый.

9. Район Советы тарафыннан территориаль иҗтимагый үзидарә чикләре билгеләнгәч, инициатив төркем территориаль иҗтимагый үзидарә оештыру буенча гражданнар җыелышын (конференциясен) чакыру процедурасын башларга хокуклы.

10. Инициатив төркем әгъзасына муниципаль берәмлек Башлыгы тарафыннан расланган форма буенча территориаль иҗтимагый үзидарәне оештыру буенча эшләрне гамәлгә ашыру хокукын раслый торган документ бирелә.

**7 маддә. Территориаль иҗтимагый үзидарә чикләрен билгеләү белән бәйле барлыкка килгән фикер каршылыкларын җайга салу тәртибе**

1. Әгәр инициатив төркем тәкъдим иткән территория башка инициатив төркем тәкъдим иткән территориягә тулысынча яки өлешчә туры килә, һәм бу территориядә территориаль иҗтимагый үзидарә оештырылмаган икән (әлеге территориягә карата район Советы территориаль иҗтимагый үзидарә чикләрен билгеләү турында карар кабул итмәгән), документларны карау түбәндәге тәртиптә гамәлгә ашырыла.

Инициатив төркем тарафыннан тәкъдим ителгән документларны алдан карауны гамәлгә ашыручы орган (алга таба-вәкаләтле орган) тиешле территориягә карата тәкъдимнәр биргән барлык инициатив төркемнәргә килеп туган хәл турында хәбәр итә һәм әлеге мәсьәләне район Советы утырышы каравына кертелгәнче, чикләрне билгеләү турында килешүгә килергә тәкъдим итә.

Күрсәтелгән килешү булмаганда, инициатив төркемнәр тарафыннан туры килүче территориянең яшәүчеләр җыелышлары үткәрелергә мөмкин, аларда әлеге территорияне теге яки бу территориаль иҗтимагый үзидарәгә кертү буенча гражданнарның фикере ачыкланырга һәм рәсмиләштерелгән булырга тиеш. Шул ук вакытта:

- җыелышның кворумы территориаль иҗтимагый үзидарәдә катнашу хокукына ия булган тәңгәл килүче территориядә яшәүчеләр саныннан билгеләнә;

- җыелышта мәҗбүри тәртиптә туры килүче территориянең 16 яшькә җиткән кимендә өчтән бер халкы катнашырга тиеш;

- җыелышта әлеге территориядә чикләрен билгеләү турында билгеләнгән тәртиптә тәкъдимнәр биргән барлык инициатив төркемнәр, тиешле сайлау округларыннан сайланган депутатлар, район Башкарма комитеты вәкилләре катнашырга хокуклы;

- туры килүче территориядә яшәүчеләргә территориянең теге яки бу территориаль җәмәгать үзидарәсе чикләренә керүе турында хәбәр ителергә тиеш;

- туры килүче территориядә яшәүчеләр территорияне территориаль иҗтимагый үзидарә чикләренә кертүнең бер варианты өчен генә тавыш бирә.

Район Советы җыелышлар беркетмәләре нигезендә чикләр билгеләү турында карар кабул итә, аларда туры килгән территорияне территориаль иҗтимагый үзидарәләрнең берсе чикләренә кертү турында, әлеге территорияләрдә яшәгән катнашучы халык, тавыш бирү нәтиҗәләре турында хәбәр булырга тиеш.

Тәңгәл килүче территория мөнәсәбәтендә башка инициатив төркемнәр тәкъдим иткән территориаль иҗтимагый үзидарәләрнең чикләре, тәңгәл килүче территорияне кертмичә, әлеге тәртипнең 6 маддәсендә билгеләнгән таләпләргә туры килүе шартында билгеләнә.

Әгәр әлеге өлешнең икенче абзацында күрсәтелгән хәбәрнамәне җибәргән көннән соң бер ай узгач, җыелыш (конференция) беркетмәләре инициатив төркем тарафыннан Башарма комитетка тәкъдим ителмәгән очракта, территориаль иҗтимагый үзидарә оештыру буенча әлеге инициатив төркемнең эше туктатылган санала.

2. Әгәр инициатив төркем тарафыннан, район Советы тарафыннан территориаль иҗтимагый үзидарә чикләрен билгеләү турында карар кабул ителгән территория белән тулысынча тәңгәл килүче территориянең чикләрен билгеләү турында тәкъдим кертелгән очракта, тәкъдим кире кагыла (әлеге тәртипнең 8 маддәсе 18 өлеше белән каралган нигезләр буенча чикләрне билгеләү турында район Советы тарафыннан электән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару очрагыннан тыш).

3. Әгәр инициатив төркем тарафыннан район Советы тарафыннан территориаль иҗтимагый үзидарә чикләрен билгеләү турында карар кабул ителгән территория белән өлешчә тәңгәл килүче территориянең чикләрен билгеләү турында тәкъдим кертелгән очракта, инициатив төркем гражданнар җыелышының (конференциясенең) электән билгеләнгән чикләрне үзгәртү белән килешү турында беркетмәсе күчермәсен тапшырырга тиеш (әлеге тәртипнең 8 маддәсе 18 өлеше белән каралган нигезләр буенча чикләрне билгеләү турында район Советы тарафыннан электән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару очрагыннан тыш). Әлеге җыелыш (конференция) территориянең электән билгеләнгән чикләрендә яшәүче гражданнары арасында уздырыла.

Әгәр җыелыш (конференция) беркетмәсенең күчермәсе тапшырылган очракта, Башкарма комитет яңадан төзелүче территориаль иҗтимагый үзидарә чикләрен билгеләү белән бер үк вакытта, рацон Советы каравына территориаль иҗтимагый үзидарәнең электән билгеләнгән чикләрен үзгәртү турында карар проектын кертә.

Җыелыш (конференция) беркетмәсенең тәртипнең 6 маддәсендә билгеләнгән таләпләргә туры килү шартында тәңгәл килүче территорияне кертмичә билгеләнергә мөмкин.

4. Әгәр билгеле бер территориядә территориаль иҗтимагый үзидарә чикләре билгеләнгән һәм мондый территориянең өлешендә яңа территориаль иҗтимагый үзидарә оештыру ниятләнгән очракта, яңадан түзелүче территориаль иҗтимагый үзидарә чикләре бер үк вакытта гамәлдәге территориаль иҗтимагый үзидарә территориясенең чикләрен үзгәртү белән билгеләнә.

Инициатив төркем әлеге территориядә яшәүче гражданнарның җыелышы (конференциясе) каравына яңа территориаль иҗтимагый үзидарә оештыру белән бәйле рәвештә гамәлдәге территориаль иҗтимагый үзидарә территориясенең чикләрен билгеләү турында тәкъдим кертә.

Территориаль иҗтимагый үзидарә территориясенең чикләрен үзгәртү турында тәкъдим территориаль иҗтимагый үзидарә уставы нигезендә җыелыш (конференция) билгеләргә вәкаләтле территориаль иҗтимагый үзидарә органына җибәрелә.

Территориаль иҗтимагый үзидарә органы, тәкъдимнәр кергән көннән бер ай эчендә җыелыш яки конференцияне билгеләргә тиеш.

Җыелыш яки конференция тәкъдимнәр кергән көннән соң ике ай эчендә үткәрелә.

Җыелышның күчермәсе (конференция) инициатив төркем вәкиленә бирелә.

Яңа территориаль иҗтимагый үзидарә оешуга бәйле рәвештә гамәлдәге территориаль иҗтимагый үзидарә чикләрен үзгәртү турында җыелыш (конференция) тарафыннан тәкъдимнәр кабул ителгән очракта гражданнарның инициатив төркеме төзелә торган территориаль иҗтимагый үзидарә чикләрен билгеләү турындагы тәкъдим белән район Советына мөрәҗәгать итә. Әлеге тәкъдимгә шулай ук гамәлдәге территориаль иҗтимагый үзидарә җыелышының яисә конференциясенең беркетмәсенең күчермәсе дә теркәлә.

Территориаль иҗтимагый үзидарә органы гамәлдәге территориаль иҗтимагый үзидарә чикләрен үзгәртү турындагы тәкъдимне шулай ук район Советына һәм Башкарма комитетка җибәрә.

Әгәр район Советына гамәлдәге территориаль иҗтимагый үзидарә чикләрен үзгәртү турында җыелыш (конференция) беркетмәсенең күчермәсе тәкъдим ителмәгән булса, территориаль иҗтимагый үзидарәнең гамәлдәге органының үз чикләрен, яңа төзелә торган территориаль иҗтимагый үзидарәнең чикләрен үзгәртү турында тәкъдиме әлеге нигезләмәнең 6 маддәсендә билгеләнгән таләпләргә туры килү шарты белән тәңгәл килүче территориядән тыш билгеләнә.

Моңа кадәр гамәлгә куелган территориаль иҗтимагый үзидарә эшчәнлеген туктату һәм аны закон нигезендә билгеләнгән тәртиптә юридик зат буларак бетерү очраклары искәрмә булып тора.

5. Үзара чиктәш ике яки аннан күбрәк территориаль иҗтимагый үзидарәләрнең берләшүе очрагында, инициатив төркем берләштерү ниятләнгән территорияләрдә яшәүче гражданнар җыелышы (конференциясе) каравына берләшү, элекке чикләрдә территориаль иҗтимагый үзидарәне гамәлгә ашыру туктатылу һәм берләшкән территориаль иҗтимагый үзидарә чикләрен билгеләү турында тәкъдим кертә.

Тәкъдимнәр һәрбер территориаль иҗтимагый үзидарә органына җибәрелә.

Территориаль иҗтимагый үзидарәнең тиешле органнары, тәкъдимнәр кергән көннән бер ай эчендә үз территорияләрендә җыелышлар яки конференцияләр билгеләргә тиеш.

Җыелышлар, конференцияләр тәкъдимнәр кергән көннән алып ике айдан да артмаган вакытта үткәрелә.

Җыелышлар яки конференцияләр беркетмәләренең күчермәләре инициатив төркем вәкиленә бирелә.

Барлык территориаль иҗтимагый үзидарәләрнең җыелышлары (конференцияләре) тарафыннан аларның берләшүе, элекке чикләрдә территориаль иҗтимагый үзидарәне гамәлгә ашыру туктатылу һәм берләшкән территориаль иҗтимагый үзидарә чикләрен билгеләү турында тәкъдим кабул ителгән очракта, гражданнарның инициатив төркеме район Советына аның чикләрен билгеләү турында тәкъдим белән мөрәҗәгать итә. Аңа шулай ук гамәлдәге территориаль иҗтимагый үзидарәләрнең җыелышлары (конференцияләре) карарларының күчермәләре теркәлә.

Юридик зат сыйфатында теркәлгән территориаль иҗтимагый үзидарәләрне берләштерү юридик затларны үзгәртеп оештыру өчен гражданнар законнары белән билгеләнгән хокукый нәтиҗәләргә китерә.

6. Территориаль иҗтимагый үзидарә икегә яки берничәгә бүленгән очракта, инициатив төркем бүлү ниятләнгән территорияләрдә яшәүче гражданнар җыелышы (конференциясе) каравына территориаль иҗтимагый үзидарәне бүлү, элекке чикләрдә территориаль иҗтимагый үзидарәне гамәлгә ашыру туктатылу һәм төзеләчәк территориаль иҗтимагый үзидарә чикләрен билгеләү турында тәкъдим кертә.

Тәкъдим территориаль иҗтимагый үзидарә уставы нигезендә җыелыш (конференция) билгеләргә вәкаләтле территориаль иҗтимагый үзидарә органына җибәрелә.

Җыелыш яки конференция тәкъдимнәр кергән көннән алып ике айдан да артмаган вакытта үткәрелә.

Җыелыш яки конференция беркетмәсенең күчермәсе инициатив төркем вәкиленә бирелә.

Җыелыш (конференция) тарафыннан иҗтимагый үзидарәне бүлү, элекке чикләрдә территориаль иҗтимагый үзидарәне гамәлгә ашыру туктатылу һәм төзеләчәк территориаль иҗтимагый үзидарә чикләрен билгеләү турында тәкъдим кабул ителгән очракта, гражданнарның инициатив төркеме аларның чикләрен билгеләү турында тәкъдим белән район Советына мөрәҗәгать итә. Аңа шулай ук гамәлдәге территориаль иҗтимагый үзидарә җыелышы (конференциясе) карарының күчермәсе теркәлә.

Юридик зат сыйфатында теркәлгән территориаль иҗтимагый үзидарәләрне бүлү юридик затларны үзгәртеп оештыру өчен гражданнар законнары белән билгеләнгән хокукый нәтиҗәләргә китерә.

**8 маддә. Территориаль иҗтимагый үзидарә оештыру максатында гражданнар җыелышын (конференциясен) уздыру тәртибе**

1. Җыелыш (конференция) уздыруны гражданнарның инициатив төркеме тәэмин итә.

2. Әгәр территориаль иҗтимагый үзидарәне гамәлгә ашыру ниятләнән территориядә 300 дән артык кеше яшәгән очракта, оештыру конференциясе үткәрелә.

3. Оештыру конференциясенә делегатлар саны вәкиллек нормасыннан чыгып билгеләнә:

1) 20 гражданнан 1 делегат - әгәр тиешле территориядә уналты яшькә җиткән 1000 гә кадәр граждан яшәсә;

2) 200 гражданнан 1 делегат - әгәр тиешле территориядә уналты яшькә җиткән 1000 нән алып 10000 гә кадәр граждан яшәсә;

3) 300 гражданнан 1 делегат - әгәр тиешле территориядә уналты яшькә җиткән 10000 нән артык граждан яшәсә.

4. Аз катлы шәхси төзелеш территориясендә территориаль иҗтимагый үзидарә төзегән очракта, конференциягә делегатлар сайлау буенча вәкиллек нормасы 10 нан да ким булмаган һәм 30 дан да артмаган йорт биләмәсенә 1 делегат тәшкил итәргә тиеш.

5. Делегат конференциягә гражданнар җыелышында яки гражданнарның имзасын җыю юлы белән сайлана.

6. Инициатив төркем тиешле территориядә яшәүчеләргә җыелыш (конференция) чакыру, уздыру датасы, вакыты һәм урыны турында аны уздыруга 10 көн кала, мәгъүмат барып җитә алуны тәэмин итәрлек теләсә нинди формада (белдерүләр урнаштыру, фатирларны йөреп чыгу һ.б.), шулай ук язма формада район Советына, Башкарма комитетка хәбәр итә.

7. Җыелыш яки конференция башланыр алдыннан җыелышка яки конференциягә килгән тиешле территориядә яшәүчеләрне (конференция делегатларын) теркәү үткәрелә.

8. Җыелышта яки конференциядә рәислек итүче һәм сәркатип сайлана. Җыелышның рәисен һәм секретарен сайлаганчы (конференция), җыелыш яки конференцияне инициатив төркем әгъзаларының берсе ача һәм алып бара.

9. Җыелыш яки конференцияне үткәрү процедурасы җыелыш яки конференция секретаре тарафыннан ирекле язма рәвештә алып барыла торган беркетмәдә чагылдырыла һәм җыелыш яки конференция рәислек итүче һәм секретаре тарафыннан имзалана.

10. Җирле үзидарә органнары оештыру җыелышында яки конференциядә катнашу өчен үзенең вәкилен киңәш бирү тавышы хокукы белән җибәрергә хокуклы.

11. Оештыру җыелышында яки конференциядә карарлар кабул ителә:

1) тиешле территория чикләрендә территориаль иҗтимагый үзидарә булдыру турында;

2) территориаль иҗтимагый үзидарә органнарын сайлау турында;

3) территориаль иҗтимагый үзидарә уставын кабул итү турында;

4) территориаль иҗтимагый үзидарә уставын теркәү белән бәйле мәсьәләләрне караганда территориаль иҗтимагый үзидарә вәкилен (вәкилләрне) сайлау турында.

Күрсәтелгән карарлар ачык тавыш бирү юлы белән гади күпчелек тавыш белән кабул ителә.

11. Әгәр җыелышта тиешле территориядә яшәүчеләрнең уналты яше тулмаган өчтән бер өлеше катнашса, җыелыш хокуклы санала.

12. Конференция, тиешле территориядә яшәүчеләрнең уналты яшькә җиткән өчтән береннән дә ким булмаган өлешен тәшкил иткән сайланган делегатларның өчтән икесе катнашса, конференция хокуклы санала.

13. Территориаль иҗтимагый үзидарәне гамәлгә ашыручы гражданнар җыелышының (конференциясенең) аерым вәкаләтләренә керә:

1) җыелыш (конференция) уздыру хокукы (кворум турында);

2) тиешле территория чикләрендә территориаль иҗтимагый үзидарәне оештыру;

3) территориаль иҗтимагый үзидарә уставын кабул итү, аңа үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү;

4) территориаль иҗтимагый үзидарә органнары структурасын билгеләү:

5) территориаль иҗтимагый үзидарә органнарын сайлау;

6) территориаль иҗтимагый үзидарә эшчәнлегенең төп юнәлешләрен билгеләү;

7) территориаль иҗтимагый үзидарәнең керемнәр һәм чыгымнар сметасын һәм аның үтәлеше турында хисапны раслау;

8) территориаль иҗтимагый үзидарә органнары эшчәнлеге турында хисапларны карау һәм раслау;

9) территориаль иҗтимагый үзидарә уставын теркәү белән бәйле сорауларны караганда территориаль иҗтимагый үзидарәне тәкъдим итәргә вәкаләтле вәкилне (вәкилләрне) сайлау.

14. Әлеге нигезләмәнең 13 өлешендә күрсәтелгән карарлар ачык тавыш бирү юлы һәм күпчелек тавыш белән кабул ителәләр.

15. Әгәр район Советының территориаль иҗтимагый үзидарә чикләрен билгеләү турында карары үз көченә кергән көннән соң 30 көн эчендә территориаль иҗтимагый үзидарә уставын теркәү өчен документлар тапшырылмаган очракта, территориаль иҗтимагый үзидарәне оештыру буенча гамәлләр туктатылган санала. Район Советының чикләрне билгеләү турында карары гамәлдән чыгарыла.

## 9 маддә. Территориаль иҗтимагый үзидарә уставы

1. Территориаль иҗтимагый үзидарә уставында бигеләнә:

1) ул гамәлгә ашырылган территория;

2) территориаль иҗтимагый үзидарә эшчәнлегенең максатлары, бурычлары, формалары һәм төп юнәлешләре;

3) территориаль иҗтимагый үзидарә органнары формалашу тәртибе, вәкаләтләре туктатылу, хокуклары һәм вазифалары, вәкаләтләр срогы;

4) карарлар кабул итү тәртибе;

5) милек алу тәртибе, шулай ук әлеге милектән һәм финанс средстволарыннан файдалану һәм идарә итү тәртибе;

6) территориаль иҗтимагый үзидарәне гамәлгә ашыру туктатылу тәртибе.

## 10 маддә. Территориаль иҗтимагый үзидарә уставын теркәү тәртибе

1. Юридик зат оештырмыйча территориаль иҗтимагый үзидарә уставын Тукай районы Башлыгы - аның территориаль органнары (авыл Советы Башлыгы) тарафыннан теркәлгән вакыттан гамәлгә куелган дип санала.

2. Территориаль иҗтимагый үзидарә уставын теркәү территориаль иҗтимагый үзидарә уставын теркәү журналына язылу юлы белән башкарыла.

Территориаль иҗтимагый үзидарә уставын теркәү вакыты дип территориаль иҗтимагый үзидарә уставын теркәү журналында язылу датасы санла.

3. Территориаль иҗтимагый үзидарә уставын теркәү өчен район Башлыгына тәкъдим ителә:

- территориаль иҗтимагый үзидарә уставын теркәү турында гражданнар җыелышының барлык вәкаләтле вәкилләре тарафыннан имзаланган гариза;

- территориаль иҗтимагый үзидарә төзү турында карар кабул ителгән гражданнар җыелышы яки конференциясе беркетмәсе (вәкаләтле вәкилләрнең фамилиясе, исеме, атасының исеме, туу датасы, паспорт яки паспортны алыштыручы документның, сериясе, номеры һәм бирелү датасы, яшәү урыны адресы күрсәтелгән);

- территориаль иҗтимагый үзидарә уставының ике нөсхәсе.

4. Югарыда күрсәтелгән документлар тапшырылганнан соң 1 ай эчендә район Советы территориаль иҗтимагый үзидарә уставын теркәү яки теркәлүдән баш тарту турында карар кабул итә.

5. Территориаль иҗтимагый үзидарә уставын теркәүдән баш тарту өчен нигез булып тора:

1) территориаль иҗтимагый үзидарә уставының Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Татарстан Республикасы Конституциясенә һәм Татарстан Республикасы законнарына, муниципаль берәмлек уставына, башка муниципаль хокукый актларга каршы килүе;

2) территориаль иҗтимагый үзидарәне оештырганда муниципаль берәмлек уставында һәм әлеге нигезләмәдә каралган тәртипне үтәмәү;

3) теркәлү өчен кирәкле барлык документларны тапшырмау.

6. Территориаль иҗтимагый үзидарә уставының теркәлгән нөсхәсе яисә аны теркәүдән язма мотивацияләнгән баш тарту гражданнарның җыелыш (конференция) вәкиленә тиешле карар кабул ителгәннән соң 5 көн эчендә җибәрелә.

7. Территориаль иҗтимагый үзидарә уставына кертелә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр территориаль иҗтимагый үзидарә уставын теркәү тәртибенә охшаш тәртиптә теркәлергә тиеш. Әгәр Россия Федерациясе законнары белән башкача билгеләнмәгән булса, күрсәтелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр аларны теркәү көненнән үз көченә керә.

8. Юридик зат буларак оешкан территориаль иҗтимагый үзидарә коммерциясез оешманың оештыру-хокукый формасында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә алынырга тиеш.

**11 маддә. Территориаль иҗтимагый үзидарәне гамәлгә ашыруны туктату, территориаль иҗтимагый үзидарә органнары вәкаләтләрен туктату тәртибе**

1. Территориаль иҗтимагый үзидарә вәкаләтләрен туктату тәртибе аның уставы белән билгеләнә.

2. Юридик зат булган территориаль иҗтимагый үзидарә эшчәнлеге юридик затны бетерү өчен гамәлдәге законнарда каралган тәртиптә туктатыла.

3. Юридик зат булмаган территориаль иҗтимагый үзидарә эшчәнлеге гражданнарның җыелышы яки конференциясе карары буенча яисә территориаль иҗтимагый үзидарә органнарының вәкаләтләре срогы чыккан очракта, 6 ай эчендә гражданнарның җыелышлар яисә конференцияләре тарафыннан яңа органнар сайланмаса, туктатылырга мөмкин.

4. Территориаль иҗтимагый үзидарә органнарының вәкаләтләре территориаль иҗтимагый үзидарә уставында каралган очракларда һәм тәртиптә, шулай ук территориаль иҗтимагый үзидарә уставында билгеләнгән срок чыкканнан соң туктатыла.

5. Территориаль иҗтимагый үзидарә органнарының вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылырга мөмкин:

1) территориаль иҗтимагый үзидарә органнарының вәкаләтләрен туктату турында гражданнар җыелышы яки конференциясе карарлары;

2) гамәлдәге закон таләпләрен бозган очракта, суд карары законлы көченә керү;

3) территориаль иҗтимагый үзидарә уставында каралган башка очракларда.

## 3 бүлек. Территориаль иҗтимагый үзидарә органнары

**12 маддә. Территориаль иҗтимагый үзидарә органнары**

1. Территориаль иҗтимагый үзидарәнең иң югары органы булып территориаль иҗтимагый үзидарәне гамәлгә ашыру буенча гражданнар җыелышы яки конференциясе тора. Территориаль иҗтимагый үзидарә гражданнарның җыелышлары яисә конференцияләре тарафыннан турыдан-туры гамәлгә ашырыла ала.

2. Территориаль иҗтимагый үзидарә уставы нигезендә гражданнарның җыелышы яки конференциясе карары буенча территориаль иҗтимагый үзидарә органнары төзелергә мөмкин.

3. Территориаль иҗтимагый үзидарә органнары сыйфатында булырга мөмкин:

1) территориаль иҗтимагый үзидарәнең бер генә кеше идарә итә торган органнары (территориаль иҗтимагый үзидарә рәисе, казначысы һ.б.);

2) гражданнарның җыелышы яки конференциясе арасында территориаль иҗтимагый үзидарә исеменнән эш йөртүче территориаль иҗтимагый үзидарәнең коллегиаль органнары (комитетлар, советлар һ.б.).

4. Территориаль иҗтимагый үзидарә органнарының вәкаләтләрен, хокукларын һәм бурычларын формалаштыру, туктату тәртибе, вәкаләтләре вакыты, алар тарафыннан карарлар кабул итү тәртибе территориаль иҗтимагый үзидарә уставы белән билгеләнә.

**13 маддә. Территориаль иҗтимагый үзидарә органнары вәкаләтләре**

1. Территориаль иҗтимагый үзидарә органнары:

1) тиешле территориядә яшәүче халык мәнфәгатьләрен кайгырталар;

2) гражданнар җыелышларында һәм конференцияләрендә кабул ителгән карарларның

үтәлешен тәэмин итәләр;

3) торак фондын карап тоту, территорияне төзекләндерү буенча хуҗалык эшчәнлеген, тиешле территориядә яшәүче гражданнарның социаль-көнкүреш ихтыяҗларын канәгатьләндерүгә юнәлдерелгән башка хуҗалык эшчәнлеген башкара ала;

4) бу органнар һәм җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары тарафыннан мәҗбүри каралырга тиешле муниципаль хокукый актлар проектларын район Советына, муниципаль берәмлек башлыгына һәм район башкарма комитетына кертергә хокуклы.

2. Территориаль иҗтимагый үзидарә органнарының башка хокуклары һәм бурычлары гамәлдәге законнар, муниципаль хокукый актлар нигезендә территориаль иҗтимагый үзидарә уставы белән билгеләнә.

### 14 маддә. Гражданнарның җыелышы яки конференциясе

1. Территориаль иҗтимагый үзидарәне гамәлгә ашыру максатында гражданнарның җыелышларын (конференцияләрне) билгеләү һәм үткәрү тәртибе аның уставы белән билгеләнә һәм җыелышны (конференцияләрне) үткәрү вакыты һәм урыны турында гражданнарга үз вакытында хәбәр итүне күздә тотарга тиеш.

2. Территориаль иҗтимагый үзидарәне гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча гражданнар җыелышы, әгәр тиешле территориядә яшәүчеләрнең анда уналты яше тулган өчтән береннән дә ким булмаган өлеше катнашса хокуклы санала.

3. Конференция, тиешле территориядә яшәүчеләрнең уналты яшькә җиткән өчтән береннән дә ким булмаган өлешен тәшкил иткән сайланган делегатларның өчтән икесе катнашса, хокуклы санала.

4. Территориаль иҗтимагый үзидарәне гамәлгә ашыручы гражданнар җыелышының (конференциясенең) аерым вәкаләтләренә керә:

1) территориаль иҗтимагый үзидарә органнары структурасын билгеләү;

2) территориаль иҗтимагый үзидарә уставын кабул итү, аңа үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү;

3) территориаль иҗтимагый үзидарә органнарын сайлау;

4) территориаль иүтимагый үзидарә эшчәнлегенең төп юнәлешләрен билгеләү;

5) территориаль иҗтимагый үзидарәнең керемнәр һәм чыгымнар сметасын һәм аның үтәлеше турында хисапны раслау;

6) территориаль иҗтимагый үзидарә органнары эшчәнлеге турында хисапларны карау һәм раслау.

### 15 маддә. Территориаль иҗтимагый үзидарә рәисе

1. Территориаль иҗтимагый үзидарәнең бер генә кеше идарә итә торган органы булып гражданнарның җыелышлары (конференцияләре) тарафыннан сайлана һәм тиешле территориядә яшәүче гражданнарны гражданнар, юридик затлар, дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлары белән үзара мөнәсәбәтләрдә тәкъдим итүче территориаль иҗтимагый үзидарә рәисе тора.

2. Рәис вәкаләтләренә кертелергә мөмкин:

1) гражданнарның җыелышлар яки конференцияләрен әзерләү һәм үткәрүне оештыру;

2) гражданнарның җыелышларын (конференцияләрен) алып бару;

3) кабул ителгән карарларның үтәлешен контрольдә тоту;

4) территориаль иҗтимагый үзидарә кассалары акчаларын тоту юнәлешләрен эшләү;

5) гражданнар җыелышлары (конференцияләре) карарлары нигезендә җәмәгать кассалары чаралары белән эш итү;

6) гражданнар җыелышлары (конференцияләре) карарларына кул кую;

7) иҗтимагый характердагы башка мәсьәләләрне хәл итү.

3. Әгәр территориаль иҗтимагый үзидарә уставы белән территориаль иҗтимагый үзидарәнең коллегиаль органнары (комитетлар, советлар) каралган булса, территориаль иҗтимагый үзидарә рәисе сайланмый, ә аның функцияләрен территориаль иҗтимагый үзидарә комитеты (советы) рәисе башкара.

## 16 маддә. Территориаль иҗтимагый үзидарә казначысы

1. Территориаль иҗтимагый үзидарәнең бердәнбер финанс органы булып гражданнар җыелышы (конференциясе) тарафыннан сайлана торган территориаль иҗтимагый үзидарә акчаларын (җәмәгать кассасы) җыю, исәпкә алу һәм сарыф итүнең дөреслеге өчен җавап бирүче территориаль иҗтимагый үзидарәнең казначысы булырга мөмкин.

2. Казначы вәкаләтләренә керергә мөмкин:

1) гражданнарның акчалата взносларын исәпләү;

2) акча җыю һәм исәпкә алу;

3) территориаль иҗтимагый үзидарә рәисе тарафыннан җәмәгать кассасы чараларын куллануның дөреслеген контрольдә тоту;

4) җәмәгать кассасы акчаларын халык алдында һәм территориаль иҗтимагый үзидарә органнары алдында тоту турында хисап.

3. Әгәр территориаль иҗтимагый үзидарә уставы белән территориаль иҗтимагый үзидарәнең коллегиаль органнары (комитетлар, советлар) каралган булса, территориаль иҗтимагый үзидарә казначысы сайланмый, ә аның функцияләрен территориаль иҗтимагый үзидарә комитеты (советы) казначысы үти.

## 17 маддә. Территориаль иҗтимагый үзидарә комитетлары (советлары)

1. Территориаль иҗтимагый үзидарәнең коллегиаль органы (комитет, совет һ.б.) территориаль иҗтимагый үзидарә уставы нигезендә яшәү урыны буенча гражданнар тарафыннан җыелышта яисә конференциядә сайлана.

2. Комитет (совет) территориаль иҗтимагый үзидарә уставында билгеләнгән вакытка өч кешедән дә ким булмаган санда сайлана. Коллегиаль орган составына комитет (совет) рәисе һәм комитет (совет) казначысы керә.

3. Иҗтимагый үзидарә комитеты (советы) территориаль иҗтимагый үзидарә исеменнән гражданнар җыелышы тарафыннан кабул ителгән территориаль иҗтимагый үзидарә уставы теркәлгәннән соң, гражданнарның җыелышлары һәм конференцияләре арасында үз вәкаләтләре чикләрендә эш итә.

4. Комитет (совет) компетенциясенә түбәндәге мәсьәләләрне хәл итү кертелергә мөмкин:

1) комитет (совет) белән җитәкчелек итү территориаль иҗтимагый үзидарә уставы нигезендә территориаль иҗтимагый үзидарә рәисенә йөкләнмәгән очракта, комитет (совет) рәисен сайлау;

2) комитет (совет) әгъзалары арасыннан аның казначысын сайлау;

3) комитетның (советның) җәмәгать кассасын булдыру һәм акчаларны тоту тәртибен билгеләү;

4) муниципаль берәмлекнең органнары һәм вазыйфаи затлары белән үзара хезмәттәшлек;

5) гражданнарның җыелышлар (конференцияләр) компетенциясенә кертелмәгән башка мәсьәләләр.

5. Территориаль иҗтимагый үзидарә уставында тиешле территориаль иҗтимагый үзидарә территориясе чикләрендә яшәүче теләсә кайсы гражданның комитет (совет) утырышларында катнашу хокукы каралырга мөмкин. Гражданнарның комитет (совет) утырышында катнашу тәртибе территориаль иҗтимагый үзидарә уставы белән билгеләнергә мөмкин.

## 18 маддә. Комитет (совет) рәисе һәм казначысы

1. Комитет (совет) рәисе - территориаль иҗтимагый үзидарәнең сайланулы заты - комитет тарафыннан үз составыннан сайлана һәм гражданнар, юридик затлар, дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлары белән үзара мөнәсәбәтләрдә комитет (совет) исеменнән эш итә.

2. Комитет (совет) рәисе вәкаләтләренә территориаль иҗтимагый үзидарә рәисе өчен әлеге нигезләмә белән билгеләнгән вәкаләтләр, шулай ук комитет (совет) эшчәнлеген оештыру буенча үз вәкаләтләре керә ала.

3. Казначы - территориаль иҗтимагый үзидарәнең сайланулы заты - җәмәгать кассасы акчаларын җыю, исәпкә алу һәм тоту дөреслеге өчен җавап бирә.

4. Комитет (совет) казначысы вәкаләтләренә территориаль иҗтимагый үзидарә казначысы

өчен әлеге нигезләмә белән билгеләнгән вәкаләтләр керә ала.

5. Территориаль иҗтимагый үзидарә уставы нигезендә комитет (совет) территориаль иҗтимагый үзидарә органнарын тотуга керемнәр һәм чыгымнар сметасында каралган керемнәр кысаларында рәискә һәм казначыга акчалата түләү формаларын һәм күләмнәрен мөстәкыйль билгели.

**19 маддә. Территориаль иҗтимагый үзидарә органнары карарлары**

1. Территориаль иҗтимагый үзидарә органнары үз компетенциясе чикләрендә карарлар кабул итә. Карар кабул итү тәртибе территориаль иҗтимагый үзидарә уставы белән билгеләнә.

2. Территориаль иҗтимагый үзидарә органнары тарафыннан аларның компетенциясе чикләрендә кабул ителгән карарлар тиешле территория чикләрендә яшәүче гражданнар, шулай ук территориаль иҗтимагый үзидарә мәнфәгатьләренә һәм законлы хокукларына кагылышлы эшчәнлекне гамәлгә ашыручы башка гражданнар һәм юридик затлар тарафыннан үтәлә.

3. Территориаль иҗтимагый үзидарә органнары карарлары муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлары өчен тәкъдим итү характерына ия.

**4 бүлек. Территориаль иҗтимагый үзидарәнең икътисадый нигезе һәм гарантияләре**

**20 маддә. Территориаль иҗтимагый үзидарәнең финанс ресурслары**

1. Территориаль иҗтимагый үзидарәнең финанс ресурслары үз средстволары хисабына, үз эшчәнлеге керемнәреннән, ирекле взнослардан һәм иганәдән, шулай ук закон белән тыелмаган башка керемнәрдән формалашырга мөмкин.

2. Тукай муниципаль районы бюджетыннан средстволар бюджет законнары таләпләренә туры китереп бирелә.

3. Территориаль иҗтимагый үзидарә органнары, җирле билгеләнештәге сорауларны хәл итү буенча шәхси инициативаларны гамәлгә ашыру максатыннан, районның җирле үзидарә органнары белән килешү мөнәсәбәтенә керергә мөмкин.

4. Территориаль иҗтимагый үзидарә эшчәнлегенә гражданнарның акча взнослары күләме турында карар гражданнар җыелышы тарафыннан кабул ителә һәм күрсәтелгән взносларны кертү чоры төрлечә булырга мөмкин.

5. Гражданнарның акча взносларын исәпкә алу, саклау, куллану һәм куллануны контрольдә тоту территориаль иҗтимагый үзидарә уставы нигезендә гамәлгә ашырыла.

6. Җирле бюджет акчалары территориаль иҗтимагый үзидарә һәм район Башкарма комитеты арасында бюджет законнары таләпләре нигезендә төзелгән килешүләр нигезендә, шул исәптән бюджет акчаларының адреслы һәм максатчан характердагы принцибын үтәп бирелә ала.

7. Җирле бюджеттан акча бүлеп бирү шартлары һәм тәртибе чираттагы финанс елына шәһәр бюджетын раслаганда район Советының норматив хокукый акты белән билгеләнә.

**21 маддә. Территориаль иҗтимагый үзидарә милеге**

1. Территориаль иҗтимагый үзидарә территориаль иҗтимагый үзидарә акчалары исәбеннән сатып алынган яисә территориаль иҗтимагый үзидарә милкенә закон белән тыелмаган башка ысул белән ия булырга, алардан файдаланырга һәм эш итәргә хокуклы.

2. Мөлкәт сатып алу тәртибе, шулай ук территориаль җәмәгать үзидарәсенең мөлкәте һәм финанслары белән файдалану һәм эш итү тәртибе территориаль иҗтимагый үзидарә уставы белән билгеләнә.

**22 маддә. Территориаль иҗтимагый үзидарә эшчәнлеге гарантияләре**

1. Тукай муниципаль районы җирле үзидарә органнары:

1) районда яшәүчеләргә территориаль иҗтимагый үзидарәне гамәлгә ашыруга хокукларын тормышка ашыруга булышлык итәләр;

2) үзидарә территориясенең эшчәнлеген тәэмин итү буенча чаралар планын бергәләп эшләүне кертеп, территориаль иҗтимагый үзидарә органнарына оештыру һәм методик ярдәм күрсәтәләр;

3) территориаль иҗтимагый үзидарә органнарын эшчәнлекләре өчен кирәкле мәгълүмат белән тәэмин итәләр;

4) территориаль иҗтимагый үзидарә фикерен исәпкә алу кирәк булган сораулар исемлеген билгелиләр;

5) территориаль иҗтимагый үзидарә органнары арасындагы бәхәсләрне хәл итәргә ярдәм итәләр.

6) территориаль иҗтимагый үзидарә органнары арасында бәхәсләрне хәл итүгә ярдәм итәләр.

2. Территориаль иҗтимагый үзидарә органнарының мөрәҗәгатьләре законнарда каралган срокларда мәҗбүри каралырга тиеш.

**22 маддә. Территориаль иҗтимагый үзидарәнең дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар һәм иҗтимагый берләшмәләр белән үзара хезмәттәшлеге**

Территориаль иҗтимагый үзидарә органнары бурычларны һәм эшчәнлекнең төп юнәлешләрен гамәлгә ашырганда, законнарда билгеләнгән тәртиптә җирле үзидарә органнары, хокук саклау органнары (милициянең участок вәкаләтле затлары, балигъ булмаганнар эшләре буенча бүлекчәләре һәм башкалар), янгынга каршы хезмәт, санитария-эпидемиология күзәтчелеге, халыкны эш белән тәэмин итү, социаль яклау хезмәте органнары, торак-эксплуатация хуҗалыгы оешмалары, ветераннарның, инвалидларның иҗтимагый берләшмәләре, башка органнар, оешмалар, иҗтимагый берләшмәләр белән хезмәттәшлек итәргә хокуклы.

**23 маддә. Территориаль иҗтимагый үзидарә органнарының җаваплылыгы**

1. Территориаль иҗтимагый үзидарә органнарының җаваплылыгы алар тарафыннан законнар, муниципаль хокукый актлар бозылган очракта барлыкка килә.

2. Тиешле территориядә яшәүчеләрнең хокукларын, закон нормаларын һәм муниципаль хокукый актларны бозып кабул ителгән территориаль иҗтимагый үзидарә органнарының карарларына һәм гамәлләренә муниципаль берәмлек Башлыгы, район Советы, гражданнар тарафыннан законнарда билгеләнгән тәртиптә судка шикаять бирелергә мөмкин.

3. Территориаль иҗтимагый үзидарә органнары тиешле территориядә яшәүчеләр алдында җаваплы. Тиешле территориядә яшәүче гражданнарның ышанычын югалткан очракта, сайлап куелган затлар, территориаль иҗтимагый үзидарәнең сайланулы органы әгъзалары территориаль иҗтимагый үзидарә уставында билгеләнгән тәртиптә гражданнар җыелышы (конференциясе) карары буенча чакыртып алынырга мөмкин.